**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в статью 10 Закона Республики Татарстан «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» и Кодекс Республики Татарстан о муниципальной службе

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 июня 2018 года

**Статья 1**

Внести в статью 10 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 25 октября 2005 года № 106-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 1; 2005, № 10 (II часть); 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 10 (II часть); 2011, № 5, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 85 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (часть I) следующие изменения:

1) часть 6 изложить в следующей редакции:

«6. Устанавливаются следующие квалификационные требования к стажу государственной службы или работы по специальности, направлению подготовки, который необходим для замещения должностей государственной службы, для государственных служащих:

для замещения должностей государственной службы высшей группы должностей государственной службы – стаж государственной службы не менее трех лет или стаж работы по специальности, направлению подготовки не менее четырех лет;

для замещения должностей государственной службы главной группы должностей государственной службы – стаж государственной службы или стаж работы по специальности, направлению подготовки не менее двух лет;

для замещения должностей государственной службы категории «руководители» ведущей группы должностей государственной службы – стаж государственной службы не менее одного года или стаж работы по специальности, направлению подготовки не менее двух лет.

Квалификационные требования к стажу государственной службы или стажу работы по специальности, направлению подготовки для замещения должностей государственной службы категорий «помощники (советники)», «специалисты», «обеспечивающие специалисты» ведущей группы должностей государственной службы, всех категорий старшей и младшей групп должностей государственной службы не устанавливаются.

При определении стажа государственной службы учитывается также стаж работы на должностях федеральной государственной гражданской службы соответствующих должностных групп, воинских должностях и должностях федеральной государственной службы иных видов, государственных должностях, муниципальных должностях, должностях муниципальной службы соответствующих должностных групп, иных должностях в соответствии с федеральными законами.»;

2) в части 7 слова «и ведущей групп должностей государственной службы и категории «специалисты» главной и ведущей групп» заменить словами «группы должностей государственной службы и категории «специалисты» главной группы»;

3) дополнить частями 10 и 11 следующего содержания:

«10. В случае если должностным регламентом государственного служащего предусмотрены квалификационные требования к специальности, направлению подготовки, которые необходимы для замещения должности государственной службы, то при исчислении стажа работы по специальности, направлению подготовки в указанный стаж включаются периоды работы по этой специальности, этому направлению подготовки после получения гражданином (государственным служащим) документа об образовании и (или) о квалификации по указанным специальности, направлению подготовки.

11. В случае если должностным регламентом государственного служащего не предусмотрены квалификационные требования к специальности, направлению подготовки, то при исчислении стажа работы по специальности, направлению подготовки в указанный стаж включаются периоды работы гражданина (государственного служащего), при выполнении которой получены знания и умения, необходимые для исполнения должностных обязанностей по должности государственной службы, после получения им документа о профессиональном образовании того уровня, который соответствует квалификационным требованиям для замещения должности государственной службы.».

**Статья 2**

Внести в Кодекс Республики Татарстан о муниципальной службе (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 6 (II часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть); Собрание

законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 17 (часть I), № 52 (часть I), № 55 (часть I), № 94 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 8:

а) пункт 2 части 3 изложить в следующей редакции:

«2) к стажу муниципальной службы или стажу работы по специальности, направлению подготовки:

по высшим должностям муниципальной службы – стаж муниципальной службы не менее двух лет или стаж работы по специальности, направлению подготовки не менее четырех лет;

по главным должностям муниципальной службы – стаж муниципальной службы не менее одного года или стаж работы по специальности, направлению подготовки не менее двух лет.»;

б) в части 4 слово «старшей» заменить словами «ведущей, старшей»;

в) дополнить частями $5^1$ и $5^2$ следующего содержания:

«$5^1$. В случае если должностной инструкцией муниципального служащего предусмотрены квалификационные требования к специальности, направлению подготовки, которые необходимы для замещения должности муниципальной службы, то при исчислении стажа работы по специальности, направлению подготовки в указанный стаж включаются периоды работы по этой специальности, этому направлению подготовки после получения гражданином (муниципальным служащим) документа об образовании и (или) о квалификации по указанным специальности, направлению подготовки.

$5^2$. В случае если должностной инструкцией муниципального служащего не предусмотрены квалификационные требования к специальности, направлению подготовки, то при исчислении стажа работы по специальности, направлению подготовки в указанный стаж включаются периоды работы гражданина (муниципального служащего), при выполнении которой получены знания и умения, необходимые для исполнения должностных обязанностей по должности муниципальной службы, после получения им документа о профессиональном образовании того уровня, который соответствует квалификационным требованиям для замещения должности муниципальной службы.»;

г) в части 7 слова «для замещения ведущих должностей муниципальной службы – не менее полугода стажа муниципальной службы или одного года стажа работы по специальности» заменить словами «, направлению подготовки для замещения главных должностей муниципальной службы – не менее полугода стажа муниципальной службы или одного года стажа работы по специальности, направлению подготовки»;

2) часть 2 статьи 20 дополнить предложением следующего содержания: «В случае проведения конкурса на замещение должности руководителя территориального органа местной администрации, на который возлагается осуществление части полномочий местной администрации в сельских населенных пунктах, расположенных в поселении, городском округе, порядок формирования конкурсной

комиссии в муниципальном образовании должен предусматривать включение в число ее членов кандидатур, выдвинутых сходом граждан в каждом из этих сельских населенных пунктов.»;

3) в части 4 статьи 26 слова «в случаях, размерах и порядке, установленных законодательством Российской Федерации» заменить словами «в соответствии с законодательством»;

4) абзац первый части 1 статьи 29 после слова «работы» дополнить словом «(замещения)»;

5) статью $34^1$ изложить в следующей редакции:

«Статья $34^1$. **Подготовка кадров для муниципальной службы на договорной основе**

1. В целях формирования высококвалифицированного кадрового состава муниципальной службы органы местного самоуправления могут осуществлять организацию подготовки граждан для муниципальной службы на договорной основе в соответствии с законодательством Российской Федерации об образовании и с учетом положений Федерального закона «О муниципальной службе в Российской Федерации».

2. Договор о целевом обучении с обязательством последующего прохождения муниципальной службы (далее – договор о целевом обучении) заключается между органом местного самоуправления и гражданином и предусматривает обязательство гражданина по прохождению муниципальной службы в указанном органе местного самоуправления в течение установленного срока после окончания обучения.

3. Заключение договора о целевом обучении осуществляется на конкурсной основе.

4. Конкурс объявляется органом местного самоуправления и проводится конкурсной комиссией, образуемой в органе местного самоуправления.

5. В состав конкурсной комиссии включаются представитель нанимателя (работодатель) и (или) уполномоченные им муниципальные служащие (в том числе из подразделения по вопросам муниципальной службы и кадров, юридического (правового) подразделения, а в случае отсутствия таких подразделений – муниципальные служащие, ответственные за кадровое и юридическое (правовое) сопровождение деятельности органа местного самоуправления, в котором в соответствии с договором о целевом обучении гражданин обязуется проходить муниципальную службу), а также представители научных, образовательных и (или) других организаций, приглашаемые без указания персональных данных в качестве независимых экспертов-специалистов по вопросам, связанным с муниципальной службой. Число независимых экспертов должно составлять не менее одной четверти от общего числа членов конкурсной комиссии.

6. Состав конкурсной комиссии формируется таким образом, чтобы была исключена возможность возникновения конфликтов интересов, которые могли бы повлиять на принимаемые конкурсной комиссией решения.

7. Конкурсная комиссия состоит из председателя, заместителя председателя, секретаря и членов комиссии.

8. Информация о проведении конкурса на заключение договора о целевом обучении подлежит опубликованию в печатном средстве массовой информации, в котором осуществляется официальное опубликование муниципальных правовых актов, и размещению на официальном сайте органа местного самоуправления в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» не позднее чем за один месяц до даты проведения указанного конкурса.

9. В информации о проведении конкурса, предусмотренной частью 8 настоящей статьи, указываются группы должностей муниципальной службы, которые подлежат замещению гражданами после окончания обучения; квалификационные требования к этим должностям; перечень документов, представляемых на конкурс в соответствии с частью 11 настоящей статьи, место и время их приема; срок, до истечения которого принимаются указанные документы; дата, место и порядок проведения конкурса; конкурсные процедуры, используемые для оценки и отбора кандидатов на заключение договора о целевом обучении; тема письменного задания (в случае, если одной из используемых конкурсной комиссией конкурсных процедур является письменное задание), а также могут содержаться другие информационные материалы.

10. Право участвовать в конкурсе на заключение договора о целевом обучении имеют граждане, владеющие государственным языком Российской Федерации и впервые получающие среднее профессиональное или высшее образование по очной форме обучения за счет средств бюджетов бюджетной системы Российской Федерации. Гражданин, участвующий в указанном конкурсе, должен на момент поступления на муниципальную службу, а также в течение всего срока, предусмотренного частью 34 настоящей статьи, соответствовать требованиям, установленным Федеральным законом «О муниципальной службе в Российской Федерации» для замещения должностей муниципальной службы.

11. Гражданин, изъявивший желание участвовать в конкурсе, представляет в орган местного самоуправления:

1) личное заявление;

2) собственноручно заполненную и подписанную анкету по форме, утвержденной в соответствии с федеральным законодательством для представления в орган местного самоуправления гражданином, поступающим на муниципальную службу, с приложением фотографии;

3) копию паспорта (паспорт предъявляется лично по прибытии на конкурс);

4) копию трудовой книжки или иные документы, подтверждающие трудовую (служебную) деятельность гражданина (за исключением случаев, когда трудовая (служебная) деятельность ранее не осуществлялась);

5) заключение медицинской организации об отсутствии у гражданина заболевания, препятствующего поступлению на муниципальную службу и ее

прохождению в соответствии с Федеральным законом «О муниципальной службе в Российской Федерации»;

6) справку образовательной организации, подтверждающую, что гражданин впервые получает среднее профессиональное или высшее образование по очной форме обучения за счет средств бюджета бюджетной системы Российской Федерации, а также содержащую информацию об образовательной программе, которую он осваивает (с указанием наименования профессии, специальности или направления подготовки), о результатах прохождения гражданином промежуточных аттестаций в соответствии с учебным планом, о выполнении им обязанностей, предусмотренных уставом и правилами внутреннего распорядка образовательной организации;

7) письменное задание (в случае, если одной из используемых конкурсной комиссией конкурсных процедур является письменное задание).

12. По решению руководителя органа местного самоуправления осуществляется проверка достоверности и полноты персональных данных и иных сведений, включенных в документы, представленные гражданином в соответствии с частью 11 настоящей статьи.

13. Заседание конкурсной комиссии, на котором проводятся оценка и отбор претендентов, проходит не позднее чем через 14 календарных дней после дня окончания приема документов, указанных в части 11 настоящей статьи. О месте, дате и времени заседания конкурсной комиссии члены конкурсной комиссии уведомляются секретарем конкурсной комиссии не позднее чем за три рабочих дня до дня проведения такого заседания. Заседание конкурсной комиссии проводит председатель конкурсной комиссии, а в его отсутствие – заместитель председателя конкурсной комиссии.

14. Заседание конкурсной комиссии считается правомочным, если на нем присутствует не менее двух третей от общего числа ее членов.

15. Решения конкурсной комиссии принимаются открытым голосованием простым большинством голосов присутствующих на заседании членов конкурсной комиссии. В случае равенства голосов считается принятым то решение, за которое проголосовал председательствующий на заседании конкурсной комиссии.

16. Конкурсная комиссия оценивает претендентов на основании представленных документов, указанных в пунктах 1 – 6 части 11 настоящей статьи, а также по результатам конкурсных процедур. Конкурсные процедуры по решению органа местного самоуправления предусматривают индивидуальное собеседование, тестирование и (или) письменное задание.

17. Индивидуальное собеседование проводится в форме свободной беседы с претендентом по теме, относящейся к области и виду его будущей профессиональной служебной деятельности, в ходе которой претендент отвечает на вопросы членов конкурсной комиссии в целях оценки теоретических знаний и личностных качеств претендента.

18. Оценка теоретических знаний и личностных качеств претендента осуществляется по следующим критериям:

1) уровень теоретических знаний;

2) логическое построение ответа;

3) грамотность и культура речи;

4) уровень успеваемости претендента в образовательной организации, наличие научных публикаций, участие в научных конференциях, олимпиадах и других мероприятиях, проводимых образовательными организациями;

5) наличие профессиональной мотивации;

6) прохождение практики в органах местного самоуправления.

19. Результаты индивидуального собеседования оцениваются членами конкурсной комиссии:

1) в три балла, если претендент последовательно, в полном объеме раскрыл содержание темы;

2) в два балла, если претендент последовательно, в полном объеме раскрыл содержание темы, но допустил неточности и незначительные ошибки;

3) в один балл, если претендент последовательно, но не в полном объеме раскрыл содержание темы, допустил неточности и ошибки;

4) в ноль баллов, если претендент не раскрыл содержание темы, допустил значительные неточности и ошибки.

20. Баллы, присужденные претенденту по результатам индивидуального собеседования всеми присутствующими на заседании членами конкурсной комиссии, суммируются.

21. Тестирование претендентов проводится в соответствии с перечнем теоретических вопросов, составляемым органом местного самоуправления, на знание положений Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан, законодательства Российской Федерации и Республики Татарстан в области местного самоуправления, муниципальной службы, противодействия коррупции, а также знание вопросов, относящихся к сфере деятельности органа местного самоуправления, в котором в соответствии с договором о целевом обучении гражданин обязуется проходить муниципальную службу.

22. Оценка результатов тестирования осуществляется конкурсной комиссией исходя из числа правильных ответов, данных претендентом на вопросы теста.

23. По результатам тестирования членами конкурсной комиссии претендентам выставляется:

1) пять баллов, если даны правильные ответы на 86 – 100 процентов вопросов теста;

2) четыре балла, если даны правильные ответы на 70 – 85 процентов вопросов теста;

3) три балла, если даны правильные ответы на 51 – 69 процентов вопросов теста;

4) два балла, если даны правильные ответы на 35 – 50 процентов вопросов теста;

5) один балл, если даны правильные ответы на 20 – 34 процента вопросов теста;

6) ноль баллов, если даны правильные ответы менее чем на 20 процентов вопросов теста.

24. Письменное задание готовится претендентом в печатном виде по теме, определенной конкурсной комиссией и указанной в информации о проведении конкурса.

25. Тема письменного задания подбирается таким образом, чтобы выявить знание претендентом положений Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан, законодательства Российской Федерации и Республики Татарстан в области местного самоуправления, муниципальной службы, противодействия коррупции, а также знание вопросов, относящихся к сфере деятельности органа местного самоуправления, в котором в соответствии с договором о целевом обучении гражданин обязуется проходить муниципальную службу.

26. Критериями оценки письменного задания являются полнота раскрытия заданной темы, грамотность изложения, культура письменной речи.

27. Письменное задание оценивается членами конкурсной комиссии:

1) в три балла, если претендент последовательно, в полном объеме раскрыл содержание темы письменного задания;

2) в два балла, если претендент последовательно, в полном объеме раскрыл содержание темы письменного задания, но допустил неточности и незначительные ошибки;

3) в один балл, если претендент последовательно, но не в полном объеме раскрыл содержание темы письменного задания, допустил неточности и ошибки;

4) в ноль баллов, если претендент не раскрыл содержание темы письменного задания.

28. Баллы, присужденные претенденту по результатам оценки письменного задания всеми присутствующими на заседании членами конкурсной комиссии, суммируются.

29. Победившим в конкурсе считается претендент, набравший наибольшее суммарное количество баллов по итогам конкурсных процедур, применяемых в рамках конкурса.

30. Результаты голосования конкурсной комиссии оформляются протоколом, который подписывается председательствующим на заседании конкурсной комиссии и секретарем конкурсной комиссии.

31. Решение конкурсной комиссии об определении победителя конкурса является основанием для заключения органом местного самоуправления с претендентом, победившим в конкурсе, договора о целевом обучении.

32. Гражданам, участвовавшим в конкурсе, сообщается о его результатах в письменной форме в течение одного месяца со дня завершения конкурса.

33. Расходы, связанные с участием в конкурсе (проезд к месту проведения конкурса и обратно, наем жилого помещения, проживание, пользование услугами средств связи и другие), осуществляются гражданами за счет собственных средств.

34. Срок обязательного прохождения муниципальной службы после окончания целевого обучения устанавливается договором о целевом обучении. Указанный срок не может быть менее срока, в течение которого орган местного самоуправления предоставлял меры социальной поддержки гражданину в соответствии с договором о целевом обучении, но не более пяти лет.

35. Обязательства и ответственность сторон договора о целевом обучении устанавливаются договором о целевом обучении в соответствии с законодательством Российской Федерации.

36. Договор о целевом обучении может быть заключен с гражданином один раз.

37. Финансовое обеспечение расходов, предусмотренных договором о целевом обучении, осуществляется за счет средств местного бюджета.»;

6) абзац второй пункта 6 приложения 4 изложить в следующей редакции:

«В состав аттестационной комиссии включаются представитель нанимателя (работодатель) и (или) уполномоченные им муниципальные служащие (в том числе из подразделения, в котором муниципальный служащий, подлежащий аттестации, замещает должность муниципальной службы, из подразделения по вопросам муниципальной службы и кадров, юридического (правового) подразделения, а в случае отсутствия таких подразделений – муниципальные служащие, ответственные за кадровое и юридическое (правовое) сопровождение деятельности органа местного самоуправления, в котором муниципальный служащий, подлежащий аттестации, замещает должность муниципальной службы), а также представители научных, образовательных и (или) других организаций, приглашаемые без указания персональных данных в качестве независимых экспертов-специалистов по вопросам, связанным с муниципальной службой. Число независимых экспертов должно составлять не менее одной четверти от общего числа членов аттестационной комиссии.».

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
13 июля 2018 года
№ 50-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Дәүләт хезмәткәрләре өчен дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кирәкле дәүләт хезмәте яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары төркеме дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә өч ел дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә дүрт ел эш стажы;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш төркеме дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә икешәр ел дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажы;

дәүләт хезмәте вазыйфаларының әйдәүче төркеменең “җитәкчеләр” категориясе дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә бер ел дәүләт хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы.

Дәүләт хезмәте вазыйфаларының әйдәүче төркеменең “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)”, “белгечләр”, “тәэмин итүче белгечләр” категорияләренең, дәүләт хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәренең барлык категорияләренең дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен дәүләт хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.

Дәүләт хезмәте стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрдәге федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында, хәрби вазыйфаларда һәм башка төр федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында, дәүләт вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда, тиешле вазыйфаи төркемнәрдәге муниципаль хезмәт вазыйфаларында, федераль законнар нигезендә башка вазыйфаларда эш стажы исәпкә алына.”;

2) 7 өлештә “баш һәм әйдәүче төркемнәренең “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясе һәм дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш һәм әйдәүче төркемнәренең “белгечләр” категориясе” сүзләрен “баш төркеменең “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясе һәм дәүләт хезмәте вазыйфаларының баш төркеменең “белгечләр” категориясе” сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле 10 һәм 11 өлешләр өстәргә:

“10. Дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламентында белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре каралган очракта, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, күрсәтелгән стажга граждан (дәүләт хезмәткәре) әлеге белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча белем алу турында һәм (яисә) квалификация хакында документ алганнан соң бу белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эшләү чорлары кертелә.

11. Дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи регламентында белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре каралмаган очракта, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, күрсәтелгән стажга граждан (дәүләт хезмәткәре) дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килә торган дәрәҗәдә һөнәри белем алу турында документ алганнан соң гражданның (дәүләт хезмәткәренең) дәүләт хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәр һәм күнекмәләр алынган эшләү чорлары кертелә.”.

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:

а) 3 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча – кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә дүрт ел эш стажы булу;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары буенча – кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы булу.”;

б) 4 өлештә “Өлкән” сүзен “Әйдәүче, өлкән” сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ һәм $5^2$ өлешләр өстәргә:

“$5^1$. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре каралган булса, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, күрсәтелгән стажга граждан (муниципаль хезмәткәр) шушы белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча белем алу турында һәм (яисә) квалификация турында документ алганнан соң әлеге белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эшләү чорлары кертелә.

$5^2$. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре каралмаган булса, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, күрсәтелгән стажга гражданның (муниципаль хезмәткәрнең) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килә торган дәрәҗәдә һөнәри белем алу турында документ алганнан соң муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле белемнәр һәм күнекмәләр алган эшләү чорлары кертелә.”;

г) 7 өлештә “муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына карата квалификация таләпләрендә кимендә ярты ел муниципаль хезмәт стажы яки кимендә бер ел белгечлек буенча эш стажы” сүзләрен “муниципаль хезмәтнең баш вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләрендә кимендә ярты ел муниципаль хезмәт стажы яисә кимендә бер ел белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажы” сүзләренә алмаштырырга;

2) 20 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Җирлектә урнашкан авыл торак пунктларында, шәһәр округында җирле администрация вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру йөкләнә торган җирле администрация территориаль органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелгән очракта, муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясен төзү тәртибе аның әгъзалары арасына бу авыл торак пунктларының һәркайсында гражданнар җыены тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатураларны кертүне күздә тотарга тиеш.”;

3) 26 статьяның 4 өлешендә “Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, күләмдә һәм тәртиптә” сүзләрен “законнар нигезендә” сүзләренә алмаштырырга;

4) 29 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында “эшләгән” сүзеннән соң “(биләгән)” сүзен өстәргә;

5) $34^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$34^1$ статья. **Муниципаль хезмәт өчен кадрларны шартнамә нигезендә әзерләү**

1. Муниципаль хезмәтнең югары квалификацияле кадрлар составын булдыру максатларында җирле үзидарә органнары, мәгариф турында Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәт өчен гражданнарны шартнамә нигезендә әзерләүне оештыра алалар.

2. Киләчәктә муниципаль хезмәт узу йөкләмәсен алып максатчан уку турында шартнамә (алга таба – максатчан уку турында шартнамә) җирле үзидарә органы белән граждан арасында төзелә һәм, уку тәмамланганнан соң, гражданның күрсәтелгән җирле үзидарә органында билгеләнгән срок дәвамында муниципаль хезмәт узу бурычын алуын күз алдында тота.

3. Максатчан уку турында шартнамә төзү конкурс нигезендә башкарыла.

4. Конкурс җирле үзидарә органы тарафыннан игълан ителә һәм җирле үзидарә органында төзелә торган конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

5. Конкурс комиссиясе составына яллаучы (эш бирүче) вәкиле һәм (яисә) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәдәге, юридик (хокук) бүлекчәдәге, ә мондый бүлекчәләр булмаган очракта – максатчан уку турында шартнамә нигезендә граждан муниципаль хезмәт узарга тиеш булган җирле үзидарә органы эшчәнлеген кадрлар белән һәм юридик (хокукый) яктан тәэмин итү өчен җаваплы муниципаль хезмәткәрләр), шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр буларак фәнни, мәгариф һәм (яисә) башка оешмалардан персональ белешмәләре күрсәтелмичә чакырыла торган вәкилләр кертелә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.

6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе кабул итә торган карарларга йогынты ясарлык мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү куркынычы булмаслык итеп төзелә.

7. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

8. Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурс үткәрү хакындагы мәгълүмат, күрсәтелгән конкурс үткәрелү датасына кадәр бер айдан да соңга калмыйча, муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару гамәлгә ашырыла торган басма массакүләм мәгълүмат чарасында бастырылырга һәм

"Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органының рәсми сайтына урнаштырылырга тиеш.

9. Әлеге статьяның 8 өлешендә каралган конкурсны үткәрү турында мәгълүматта, укулар тәгәлләнгәннән соң, гражданнар биләргә тиешле муниципаль хезмәт вазыйфалары төркемнәре; бу вазыйфаларга карата квалификация таләпләре; әлеге статьяның 11 өлеше нигезендә конкурска тапшырыла торган документларның исемлеге, аларны кабул итү урыны һәм вакыты; күрсәтелгән документлар кабул ителә торган срок; конкурсның үткәрелү датасы, урыны һәм тәртибе; максатчан уку турында шартнамә төзүгә кандидатларны бәяләү һәм сайлап алу өчен кулланыла торган конкурс процедуралары; язма биремнең темасы (әгәр конкурс комиссиясе тарафыннан кулланыла торган конкурс процедураларының берсе язма бирем булса) күрсәтелә, шулай ук башка мәгълүмати материаллар бирелергә мөмкин.

10. Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчалары исәбеннән тәүге тапкыр урта һөнәри яисә югары белемне көндезге уку рәвешендә алучы гражданнар ия. Күрсәтелгән конкурста катнашучы граждан муниципаль хезмәткә кергән вакытта, шулай ук әлеге статьяның 34 өлешендә каралган бөтен срок дәвамында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

11. Конкурста катнашырга теләк белдергән граждан җирле үзидарә органына түбәндәгеләрне тапшыра:

1) шәхси гариза;

2) муниципаль хезмәткә керүче граждан тарафыннан җирле үзидарә органына тапшыру өчен федераль законнар нигезендә расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотография беркетеп;

3) паспорт күчермәсе (паспорт конкурска килгәннән соң шәхсән күрсәтелә);

4) хезмәт кенәгәсе күчермәсе яки гражданның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслый торган башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге элек башкарылмаган очраклардан тыш);

5) гражданның "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль закон нигезендә муниципаль хезмәткә керүгә һәм аны узуга каршы килә торган авыруы булмавы турында медицина оешмасыннан бәяләмә;

6) гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчалары исәбеннән тәүге тапкыр урта һөнәри яисә югары белемне көндезге уку рәвешендә алуын раслый торган, шулай ук ул үзләштерә торган уку-укыту программасы турында (һөнәр, белгечлек яисә әзерлек юнәлеше исемен күрсәтеп), уку планы нигезендә гражданның арадаш аттестацияләр узу нәтиҗәләре хакында, мәгариф оешмасының уставында һәм эчке тәртип кагыйдәләрендә каралган бурычларның аның тарафыннан үтәлүе хакында мәгълүматны үз эченә алган мәгариф оешмасы белешмәсе;

7) язма бирем (конкурс комиссиясе куллана торган конкурс процедураларының берсе язма бирем булган очракта).

12. Җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча персональ мәгълүматларның һәм әлеге статьяның 11 өлеше нигезендә граждан тарафыннан тапшырылган документларга кертелгән башка белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы тикшерелә.

13. Дәгъва итүчеләрне бәяләү һәм сайлап алу башкарыла торган конкурс комиссиясе утырышы әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгән документларны кабул итү тәгәлләнгән көннән соңгы 14 календарь көннән дә соңга калмыйча үткәрелә. Конкурс комиссиясе утырышының урыны, датасы һәм вакыты турында конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе әгъзаларына мондый утырышны үткәрү көненә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә. Конкурс комиссиясе утырышын конкурс комиссиясе рәисе, ә ул булмаган очракта – конкурс комиссиясе рәисе урынбасары үткәрә.

14. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала.

15. Конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү рәвешендә утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче тавыш биргән карар кабул ителгән дип санала.

16. Конкурс комиссиясе дәгъва итүчеләрне әлеге статьяның 11 өлешендәге 1 – 6 пунктларында күрсәтелгән тапшырылган документларга нигезләнеп, шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча бәяли. Җирле үзидарә органы карары буенча конкурс процедураларына индивидуаль әңгәмә, тест эшләү һәм (яисә) язма бирем кертелгән.

17. Индивидуаль әңгәмә дәгъва итүче белән аның булачак һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә караган тема буенча ирекле сөйләшү рәвешендә үткәрелә, аның барышында дәгъва итүче аның теоретик белемнәрен һәм шәхси сыйфатларын бәяләү максатларында конкурс комиссиясе әгъзалары биргән сорауларга җавап бирә.

18. Дәгъва итүченең теоретик белемнәрен һәм шәхси сыйфатларын бәяләү түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:

1) теоретик белемнәре дәрәҗәсе;

2) җавапны логик төзү;

3) грамоталылык һәм сөйләм культурасы;

4) дәгъва итүченең мәгариф оешмасында өлгереш дәрәҗәсе, фәнни мәкаләләре булуы, фәнни конференцияләрдә, олимпиадаларда һәм мәгариф оешмалары үткәрә торган башка чараларда катнашуы;

5) һөнәр мотивациясе булу;

6) җирле үзидарә органнарында практика узу.

19. Индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләре конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан түбәндәгечә бәяләнә:

1) өч балл, әгәр дәгъва итүче теманың эчтәлеген эзлекле рәвештә тулысынча ачып бирсә;

2) ике балл, әгәр дәгъва итүче теманың эчтәлеген эзлекле рәвештә тулысынча ачып бирсә, әмма тәгәлсезлекләр һәм зур булмаган хаталар җибәрсә;

3) бер балл, әгәр дәгъва итүче теманың эчтәлеген эзлекле рәвештә, әмма тулы булмаган күләмдә ачып бирсә, төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәрсә;

4) ноль балл, әгәр дәгъва итүче теманың эчтәлеген ачып бирмәсә, шактый зур төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәрсә.

20. Индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләре буенча дәгъва итүчегә конкурс комиссиясенең утырышта катнашучы барлык әгъзалары тарафыннан бирелгән баллар кушыла.

21. Дәгъва итүчеләргә тестлар эшләтү җирле үзидарә органы тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору законнарының нигезләмәләрен, шулай ук максатчан уку шартнамәсе нигезендә граждан муниципаль хезмәт үтәргә йөкләмә алган җирле үзидарә органы эшчәнлеге өлкәсен белүгә төзелгән теоретик мәсьәләләр исемлеге нигезендә үткәрелә.

22. Тест эшләү нәтиҗәләрен бәяләү конкурс комиссиясе тарафыннан дәгъва итүченең тест сорауларына биргән дөрес җаваплары саныннан чыгып башкарыла.

23. Тест эшләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары дәгъва итүчеләргә түбәндәге баллар куя:

1) биш балл, әгәр тест сорауларының 86 – 100 процентына дөрес җавап бирелгән булса;

2) дүрт балл, әгәр тест сорауларының 70 – 85 процентына дөрес җавап бирелгән булса;

3) өч балл, әгәр тест сорауларының 51 – 69 процентына дөрес җавап бирелгән булса;

4) ике балл, әгәр тест сорауларының 35 – 50 процентына дөрес җавап бирелгән булса;

5) бер балл, әгәр тест сорауларының 20 – 34 процентына дөрес җавап бирелгән булса;

6) ноль балл, әгәр тест сорауларының 20 процентыннан кименә дөрес җавап бирелгән булса.

24. Язма бирем дәгъва итүче тарафыннан конкурс комиссиясе билгеләгән һәм конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта күрсәтелгән тема буенча басма рәвештә әзерләнә.

25. Язма биремнең темасы дәгъва итүченең Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору законнары нигезләмәләрен, шулай ук максатчан уку шартнамәсе нигезендә граждан муниципаль хезмәт үтәргә йөкләмә алган җирле үзидарә органы эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләрне белүен ачыкларлык итеп сайлап алына.

26. Язма биремне бәяләү критерийларын бирелгән теманы ачып бирүнең тулылыгы, бәян итүнең дөреслеге, язма сөйләм культурасы тәшкил итә.

27. Язма бирем конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан түбәндәгечә бәяләнә:

1) өч балл, әгәр дәгъва итүче язма бирем темасының эчтәлеген эзлекле рәвештә тулысынча ачып бирсә;

2) ике балл, әгәр дәгъва итүче язма бирем темасының эчтәлеген эзлекле рәвештә тулысынча ачып бирсә, әмма төгәлсезлекләр һәм зур булмаган хаталар җибәрсә;

3) бер балл, әгәр дәгъва итүче теманың эчтәлеген эзлекле рәвештә, әмма тулы булмаган күләмдә ачып бирсә, төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәрсә;

4) ноль балл, әгәр дәгъва итүче язма бирем темасының эчтәлеген ачып бирмәсә.

28. Язма биремне бәяләү нәтиҗәләре буенча дәгъва итүчегә конкурс комиссиясенең утырышта катнашучы барлык әгъзалары тарафыннан бирелгән баллар кушыла.

29. Конкурс кысаларында кулланыла торган конкурс процедуралары йомгаклары буенча кушылган баллар исәбенең иң зурысын җыйган дәгъва итүче конкурста җиңүче булып санала.

30. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче һәм конкурс комиссиясе секретаре имза сала.

31. Конкурс җиңүчесен билгеләү турындагы конкурс комиссиясе карары җирле үзидарә органы тарафыннан конкурста җиңеп чыккан дәгъва итүче белән максатчан уку шартнамәсен төзү өчен нигез була.

32. Конкурста катнашкан гражданнарга аның нәтиҗәләре турында конкурс тәмамланган көннән алып бер ай эчендә язма рәвештә хәбәр ителә.

33. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына транспортта бару һәм кире кайту, торак урынын наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәт күрсәтүләреннән файдалану һәм башкалар) гражданнарның үз акчалары исәбеннән тотыла.

34. Максатчан уку тәмамланганнан соң муниципаль хезмәтне мәҗбүри узу срогы максатчан уку турындагы шартнамәдә билгеләнә. Күрсәтелгән срок максатчан уку турында шартнамә нигезендә гражданга җирле үзидарә органы тарафыннан социаль ярдәм чаралары күрсәтелгән сроктан ким була алмый, әмма ул биш елдан күбрәк булырга тиеш түгел.

35. Максатчан уку турында шартнамә якларының бурычлары һәм җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары нигезендә максатчан уку турында шартнамәдә билгеләнә.

36. Максатчан уку турында шартнамә граждан белән бер генә мәртәбә төзелә ала.

37. Максатчан уку турында шартнамәдә каралган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.";

6) 4 нче кушымтаның 6 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Аттестация комиссиясе составына яллаучы (эш бирүче) вәкиле һәм (яисә) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән бүлекчәдәге,

муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәдәге, юридик (хокук) бүлекчәдәге, ә мондый бүлекчәләр булмаган очракта – аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органы эшчәнлеген кадрлар белән һәм юридик (хокукый) яктан тәэмин итү өчен җаваплы муниципаль хезмәткәрләр), шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр буларак фәнни, мәгариф һәм (яисә) башка оешмалардан персональ белешмәләре күрсәтелмичә чакырыла торган вәкилләр кертелә. Бәйсез экспертлар саны аттестация комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.”.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 13 июль
№ 50-ТРЗ